ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ г.Казань Боерык

12.08.2020 № 229 - од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 16.05.2018 ел, 128-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр әйләнешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2нче ноябреннән 880 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 16.05.2018 ел, 128-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр әйләнешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 391-од номерлы боерыклары белән

кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3. пунктындагы 1.3.5 кече пунктының икенче кызыл юлын «мәгълүмат стендларында» сүзләреннән соң «ТР Дәүләт комитетының рәсми сайтында,» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләрнең әйләнешкә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында аларның реквизитларын һәм чыганакларын күрсәтеп, Комитетның рәсми сайтында (http://ojm.tatarstan.ru) урнаштырылган;

1.5 пунктының бишенче кызыл юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән "Күп функцияле үзәкләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең кагыйдәләрен раслау турында"гы 1376 нчы карары белән расланган , Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис)»;

1.5 пунктының алтынчы кызыл юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос аңлашыла («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 ст.2 п.). Гариза формасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 елның 6 февралендәге 57 номерлы карары (алга таба – ТР МК 57нче номерлы карары белән расланган Тәртип) белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр әйләнешенә рөхсәтләр бирү тәртибенә куелган Кушымтада китерелгән (әлеге Регламентка 1 нче кушымта).»;

2.2 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 декабрендәге 996 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 57 нче номерлы карары белән расланган Тәртипнең 1.4. пункты белән расланган Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә»;

2.4 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләп атамасы» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска) җибәрү, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көндә гамәлгә ашырыла.»

2.6 пунктының «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләп атамасы» графасында түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

«Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшыра ала торган, норматив хокукый актлар нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары,шул исәптән электрон рәвештә, аларны бирү тәртибе; документлар аларның карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма исеме»;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1нче пункты»;

2.15 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләп атамасы» графасында «Федераль закон» сүзләреннән соң « 210-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә»;

2.16 пунктының «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон, 210-ФЗ номерлы Федераль закон, әлеге Регламентның 2. 5 п.»;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләрнең әйләнешенә рөхсәтне (рөхсәт бирүдән баш тарту турында хатны) әзерләү.

Бүлек белгече, кергән документлар (белешмәләр) нигезендә, ведомствоара электрон багланышлар системасы һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә, әлеге Регламентның 2.5 пункты, биологик экспертиза бәяләмәсе нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

рөхсәт бирү турында карар проектын (рөхсәт бирүдән баш тарту турында хатны) Бүлек башлыгында рәсмиләштерү һәм килештерү;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр әйләнешенә бирелгән рөхсәтнамә (рөхсәт бирүдән баш тарту проекты) имза салу өчен рәискә (рәис урынбасарына) җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, узган процедура тәмамланганнан соң, 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәискә (рәис урынбасарына) кул куюга юнәлдерелгән, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм

юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр әйләнешенә рөхсәт проекты (рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат).»;

3.6. пункттагы 3.6.1 кече пунктының беренче кызыл юлында «Рәис» сүзеннән соң «(рәис урынбасары)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Регламентны түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләр әйләнешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КЫЗЫЛ КИТАБЫНА КЕРТЕЛГӘН СИРӘК ҺӘМ ЮККА ЧЫГУ КУРКЫНЫЧЫ АСТЫНДА БУЛГАН ХАЙВАННАР ҺӘМ ҮСЕМЛЕКЛӘР ӘЙЛӘНЕШЕНӘ РӨХСӘТ № ____

_______________________________________________________________

(хайваннарның атамасы)

_______________________________________________________________

(юридик затның тулы исеме,

_______________________________________________________________

физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме )

_______________________________________________________________

(юридик затның тулы адресы, физик затның теркәлгән урыны һәм

________________________________________________________бирелде.

паспорт белешмәләре )

Рөхсәтне биргән орган: ______________________________________

_______________________________________________________________

Бирү датасы: ______________________

Гамәлдә булу срогы: ________________________

Нигез: ____________________________________________________

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу

куркынычы астында булган хайваннарның һәм үсемлекләрнең әйләнешкә рөхсәт ителгән исемлеге һәм саны

| № | Төрнең исеме | Саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Хайваннарны һәм үсемлекләрне тоту урыны: ___________________________________
______________________________________________________________________________

Хайваннар һәм үсемлекләр кая китәчәк: ________________________________________
______________________________________________________________________________

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннарның һәм үсемлекләрнең әйләнеше өчен җаваплы затлар:_________________________________________________

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары - әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторы урынбасары имзасы________________________

________ номерлы рөхсәткә нәтиҗә.

Рөхсәтне бирү нигезләре: _______________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Рөхсәтнең мәҗбүри шартлары: ___________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Рөхсәтнең гамәлдә булу срогы: _______________________________________________
______________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары - әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторы урынбасары имзасы______________________
».

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне һәм алар тарафыннан каралган документларны алып баруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Рәис Ф.С.Батков